Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ГЫЙНВАР * 2024 * КАЗАН

1



Алмаз ХӘМЗИН

МАТУР ЯШӘСӘК ИДЕ!..

Яңа елда бөтен дөнья
Нурга күмелсен иде.
Җир шарыбыз Ае белән
Галәм иңләсен иде.

Бар йолдызлар төн бизәкләп
Җемелдәсеннәр иде.
Җиһан буйлап безнең аһәң
Шаулап таралсын иде.

Ул аһәңдә шатлык тулы
Мәгънәләр булсын иде.
Рәсәебез кыйбла табып,
Бәхетләр яусын иде.

Барлык халкы мул яшәүдән
Канәгать тойсын иде.
Туп тавышы гөрселдәвен
Акыл-уй тыйсын иде.

Сугыштан байлык җыйганнар
Михнәтен күрсен иде.
Хәрам мал урлап яшәгән
Тыгынып үлсен иде.

Депутатлар кеше өчен
Закон чыгарсын иде.
Үзләре дә пенсияне
Безнеңчә алсын иде.

Гади халык һәм түрәләр
Бертигез булса иде.
Безнең хезмәтне дә алар
Бәяли белсә иде.

Шагыйрьләр дә бер шәп шигырь
Әвәләсәләр иде.
Прозаиклар да укый торган
Роман язалса иде.

Редакторлар да укырлык
Гәҗит бастырса иде.
Журналда ирен кабарткан
Кызлар югалса иде.

Диңгездә коенып кайту
Өнгә дә керсен иде.
Тук яшәү рәвешләре дә
Чынга әйләнсен иде.

Иде дә иде инде дә...
Теләкләр шундый иде.
Шулай, эштән куанып гел,
Матур яшәсәк иде!

Сергей КОКАРЕВ

ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Әгәр бездә иң йөдәткән, теңкәгә тиеп беткән сүзне сайларга уйласалар, мин "кешбэк" сүзен тәкъдим итәр идем. Бүген ул бәйләнчек реклама сюжетларында үзләрен "йолдызлар" дип атаучы эстрада һәм кино артистлары авызыннан һәр почмакта яңгырый. Ә күптән түгел телевидениедән бер икътисадчы кешбэкны заманабызның Нобель премиясенә лаеклы даһи сүзе дип атады.

И. ГАРИФУЛЛИН

КАЗАН

– Аны юкка гына бүгенге көн сүзе дип уйлыйлар, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Кайчандыр пыяла шешәләр тапшырырга йөргән һәр кеше аның белән күптән таныш.**

Николай ЧЕРНЫШОВ



Ринат АБЗАЛОВ

БАЛА-ЧАГА ТҮГЕЛ...

Балачактан сеңгән саф гаделлек
Шытырдатып тота күңелне.
Тамак кырып, җитди сөйләшкәндә
Ялганчы күк тоям үземне.

Күзләренә карап кабахәтнең,
Килә барысын әйтеп бирәсе:
Фәлән абзый, синең кара җаның
Күзләреңә чыккан, диясе;

Кимсеткәндә мәльгунь кешеләрне,
Булса да ул шәһәр түрәсе –
Күпләп акыл сатып тормый гына,
Чыраена менеп төшәсе;

Зур каракны тотып кулларыннан
Бар дөньяга шәрран ярасы,
Җилтерәтеп тотып җилкәсеннән,
Прокурорга алып барасы;

Тузган бишмәт кигән карт әбине
Хәер сорап торган чагында,
Алып китеп аны, күрсәтергә
Госдуманың утырышында;

Һәм сорарга: әй сез, тук абзыйлар,
Илебезнең эшчән атлары,
Биргән вәгъдәләрне үтәвегез
Шулмы, халык депутатлары?

Ләкин ялган һәм хаксызлык күрсәм,
Читкә борам үзем йөземне.
Чөнки күптән бала-чага түгел –
Өлкән итеп тоям үземне...

Валентин ДУБИНИН

ТИШЕК КӨПЧӘК

ЗАКОН ТОЗАГЫНДА

Ни дисәң дә, хәтта кибет киштәләре сыгылып торганда да, без дефицит иле булып калабыз. Йә карабодай ярмасы юкка чыга, йә бәдрәф кәгазе җитештерү сатып алучының мәнфәгатьләрен каплый алмый, йә гади тавык йомыркалары алтынга әверелә. Әле кичә генә үзенең байлыгы белән шатландырып торган автомобильләр сату өлкәсен дә дефицит читләтеп үтмәде. Узган ел эчендә генә илне 45 машина җитештерүче ташлап китте. Бөтен калган нәрсә – халык кабул итмәгән ватан автопромы һәм кытай дуслардан килгән шикле "арба"лар. Ә без инде сыйфатлы һәм кәттә автомобильләрдә җилдерергә ияләнгән…

Тик табышлы урын, билгеле булганча, буш тормый. Күрелмәгән үсештәге "дүрт көпчәкле" кризис йоклап ятучы алыпсатарларны уятты, һәм алар якын күршеләрдән элекке чаклардагы кебек иномаркалар куып кайтарырга керештеләр. Ләкин моңа түрәләрнең нык кына ачуы чыкты бугай. Нигә соң без үзебезнең "арба"ларга күчеп утырырга тиеш тә, ә гади салым түләүчеләр иномаркада җилдерергә тиеш? Һәм тиз генә – шау-шусыз чит илләрдән кертелгән автомобильләргә утиль салымын йөзәр (!) тапкырга күтәреп куйдылар..

Көтмәгәндә меңләгән тыңлаучан машина йөртүчеләр утиль тозагына эләккән булып чыкты. Хәзер алар сатып алынган машинаны аның тагын бер бәясен түләгәч кенә рәсмиләштерә алалар. Казанда яшәүче бер ханым нәкъ шундый хәлдә калган. Аңа Кыргызстаннан миллион ярымлык Mitsubishi Outlander кайтартканнар. Аның өчен утиль салымы башта 5500 сум булган, ә бары тик бер атнадан ул 1 миллион 280 меңгә кадәр үскән. Бичара хатын нишләргә белми. Машина өчен акча кредитка алынган, хәзер аны сату да мөмкин түгел, кире кайтарып та булмый, тагын бурычка керү – башыңны элмәккә тыгуга тиң, өстәвенә, көн саен пеня тамып тора.

Ярык тагаракка әверелгән "тимер ат" янында тагын бер казанлы калган. Ир кешегә Әрмәнстан аша 2 миллион 600 мең сумлык Jeep Grand Cherokee кайтып төшкән, ә әлеге дә баягы салым 840 мең сумга тарткан. "Мондый чамадан арткан салымга мәгънә дә, мөмкинлегем дә юк", – дип уфтана ул.

Шулай да аптырашта калган автомобиль ияләре өчен бер юаныч уйлап чыгарганнар. Утиль салымын льгота буенча түләр өчен өч шарт куела: машина шәхси файдалану өчен генә кертелгән булырга тиеш, аны өч ел эчендә сатарга ярамый, ул Европа–Азия икътисадый союзына керүче илдә теркәлгән булырга тиеш. Әмма, гадәттәгечә, соңгы пункт белән катлаулыклар килеп чыгуы мөмкин. Ул союз әгъзалары өчен Россия законнары булды ни дә, булмады ни, шуңа күрә алар бернинди дә документ бирмиләр.

Автомобиль кирәк-яраклары арасында иң кирәклесе акча янчыгы икәнен руль артында йөрүчеләр бик яхшы белә. Машиналы булу шулкадәр кыйммәткә төшә ки, моңа бернинди дә илебез юлларында йөреп чыныккан нервылар җитмәс. Зыян күрүчеләр хатлар язалар, видеомөрәҗәгатьләр төшерәләр, гаделлек таләп итәләр һәм кеше талаучы законны гамәлдән чыгаруны сорыйлар. Ә ул арада, сатып алган тимер атлар, пеня суырып, үз сәгатен көтә…

Бу каршы тору нәрсә белән тәмамланыр – моны вакыт күрсәтер. Ә хәзергә беренче чиратта алыпсатарлар белән көрәш һәм илдә эшләнгән "көпчәкле чиләкләр"не популярлаштыру тора. Инде шулай килеп чыккан икән, күптән түгелге тәҗрибәне истә тотып, машинада ул бөтен гомергә җитәрлек итеп йөрергә кирәк. Ә иң мөһиме – бетмәс-төкәнмәс закон тозакларына эләкмичә генә аны сатып алу.

Людмила САФИУЛЛИНА

СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

Бөтен кеше дә машинада йөри белә, ләкин барысы да йөртә белми.

Бездә тизлекне бердәнбер чикләүче нәрсә – фаралары белән «күз кысып» каршыга килүче машина.

Әгәр дә сез башкалада «бөке»гә эләккәнсез икән, иң хәерлесе машинагызны сатып, светофорга якынрак торган автомобиль сатып алу.

Акрынрак барсаң – азрак тиеш булырсың.

Иң шәп йөртүче – син үзең. Калганнары йә башсыз җилкуар, йә ташбака.

«Яткан полицейский» әйбәт тә әйбер инде. Тизлекне дә чикли, өстеннән узу да рәхәт.

Бездәге машина йөртүченең ахмаклык дәрәҗәсе – автомобиленең куәтенә таңгал.

Сәяси карикатура КОНКУРСЫ

Валерий ТАРАСЕНКО



Сергей АНДРИАНОВ

Сергей КОКАРЕВ

• • •

Компьютер уеннары килеп чыккач, ирләргә йортлар төзү күпкә җайланды, агач утыртулар да, һәм уллар үстерү дә.

• • •

– Бу банкирларны аңламассың!
– Ни өчен?
– Алар башта: "Акча ал!" – дип, ә алгач та: "Акча бир!" – дип шалтырата башлыйлар.

• • •

ГАИ хезмәткәренә кыскача кулланма: "Әгәр машина йөртүче куркынычсызлык каешын эләктереп куйган һәм сәгатенә 60 километр тизлекне арттырмыйча барса, светофор каршында сары төскә ашыгып кереп китмәсә, сабырлык белән йөк машинасы артыннан барып, "переход" аша җәяүлеләрне уздырып җибәргән һәм бернинди дә юл йөрү кагыйдәләрен бозмаган икән, аның шпион булуы бик ихтимал".

• • •

Вокзалларда вак бәлешләр сатып торучылар үзләрен берничек тә куркыныч астына куймыйлар. Әйтик, бәлеш Красноярскида ашадың ди, ә эчең Хабаровскида авырта башлый... Нәрсә, кире барып кыйнап кайтасыңмы әллә аны?

• • •

– Салым декларациясендә унҗиде күчмә милек объектын күрсәтмәүне нәрсә белән аңлатыр идегез?
– Тыйнаклык белән.

Тегүче бик җентекләп заказ бирүченең материалын үлчи. Тегесе, түземлелеге бетеп:
– Нәрсәгә алай нык тырышасыз, үзегезгә дә калдырырга телисезме?
– Миңа нишләсәм дә җитә, сезгә дә калсын дип тырышам мин...

• • •

– Әти, Адамның тёщасы ни исемле булган?
– Аның тёщасы булмаган, улым... Ул оҗмахта яшәгән.

• • •

– Сезне ни өчен утырттылар?
– Күз алдына китерегез әле: бервакыт шунысы ачыкланды, дәүләт нәкъ минеке төсле банкнотлар чыгара башлаган икән бит.

ӨЕГЕЗДӘ УТЫРЫГЫЗ!

Татарстан, әлбәттә, кунакчыл як. Тик шулай да Чаллыдагы 60 нчы комплекста яшәүчеләрне микрорайоннарында мигрантлар өчен хостел ачу планнары борчуга салды. Югыйсә монда инде миграция үзәге дә эшләп килә. Безнең кешеләр киң күңелле булса да, "алыштыргысыз белгечләр" өчен торак барлыкка килү аларның күңеленә шом сала, балаларының элеккечә рәхәтләнеп урамда йөри алуларына шикләнә башлыйлар. Төрле инстанцияләргә күпсанлы мөрәҗәгатьләр, гадәттәгечә, нәтиҗәсез калды. Моны хәл итү өчен Тикшерү комитеты башлыгы Александр Бастрыкинга алынырга туры килде. Шуннан соң гына, җирле кешеләр фикеренчә, җәмгыять туклануы бинасын законсыз рәвештә хостел итеп үзгәртергә рөхсәт биргән Башкарма комитеты әһелләренә карата җинаять эше кузгатылды.

СКЛАДТАГЫ ЛАБОРАТОРИЯ

Милли "Мәгариф" кысаларында республика мәктәпләрендә укучылар өчен чын фәнни тәҗрибәләр ясарга мөмкинлек бирүче цифралы лабораторияләр барлыкка килгән. Ләкин Теләче районының Алан мәктәбендә заманаың гаҗәеп могҗизасы балаларга барып җитмәгән – килгән 600 мең сумлык лабораторияләр балансска куелмаган килеш складта тузан җыеп ятканнар. Ваемсызлыкмы бу, әллә мәгариф әһелләренең яңа технологияләрне үзләштерергә башлары җитмәү нәтиҗәсеме – монысы билгесез. Тик гаеплеләр инде административ җаваплылыкка тартылган.

УРЛАШЫП ЯХШЫРТУ

Бөгелмә районында коммуналь инфраструктураны яхшырту проекты удар темплар белән тормышка ашырылган, ә яхшыру нигәдер сизелмәгән. Бу хәл белән прокуратура кызыксына башлаган һәм финанслау ягыннан аңлашылмаучылыкларга тап булган. Субподряд оешмаларының берсендә хезмәткәрләрнең 2 миллион сум урлаганлыгы ачыкланган. Алар җитез рәвештә эшне кабул итү һәм түләү турында ялган документлар төзегәннәр, шулай ук килешенүдә каралмаган җиһазлар китереп торганнар. Тикшерү эшләре бару сәбәпле, ЖКХның хәлен яхшырту – билгесез вакытка кичерелеп торачак.

ОЛЫ ҖАНЛЫ ХЕЗМӘТКӘР

Бөгелмә колониясе хезмәткәре тоткыннарга ярдәм итәргә булган. Алар иректәгеләр белән даими элемтәдә булсыннар өчен, кәрәзле телефоннар белән тәэмин итеп торган. Олы җанлы хезмәткәр гаджетларны әлегә ачыкланмаган бәндәләрдән алган, ә аннан соң, мөмкинлектән файдаланып, аларны зона эченә алып кергән. 11 телефон өчен ул 24 мең сум алган һәм биографиясенә тап төшергән.







БАТУЛЛИЗМНАР

• Элек хатыннарның чәче озын, акылы кыска иде, хәзер чәче дә, акылы да кыска. Элек ирләр акыллы-сакаллы иде, хәзер сакал да юк, акыл да.

• Русиядә миһербан һәрвакыт нәҗестә, нәҗес тәхеттә булды.

• "Тукай"ны алыр өчен усал әсәр язарга кирәк яки бүләк дауларлык усал хатынга өйләнергә кирәк.

• Базарда иң кыйбат, иң үтемле товар – Татар теле. Ана телен сатып баеганнар бар. Иң елгыр бизнесменнарны Гиннесс китабына кертергә кирәк.

• Мәхәббәт белән генә өйләнешсәләр, дөньяда җиде миллиард түгел, җитмеш кеше дә булмас иде.

• Батарея – суык чакта сапсалкын, җылы чакта кап-кайнар бер нәрсә.

• Сыер – бер тапкыр ашатып, өч тапкыр саву өчен биоҗайланма.

• Хатын-кыз – ир-ат белән тигез хокуклы булам, дип, тәмәке тартып, аракы эчеп, күлмәген салып, чалбар кигән бер зат.

• Бүрелеген җуйган бүре бүрек булыр.

Рабит БАТУЛЛА

ГАФФАРИЗМНАР

• Сезгә мин кирәк чакта мин – бар, миңа кирәк чакта сез – юк. Беркем дә безнең өчен үлмәс, үзебезгә туры килер.

• Эшеңнең тар-мар ителүен теләсәң, аны югарыда килештерә башла.

• Бәрәкәтсез тотсаң, чишмә дә корый.

• Үлем сәбәбен үлемнән эзләмә.

• Кайдандыр җил иссә, татарның яфрагы леперди.

• Уй белән уй, йөрәк белән йөрәк, җан белән җан арасына төннек кирәк.

• Куркак адәм гел батырлык турында сөйләп йөри.

• Су ташырга – иләк, сүз ташырга – чиләк.

• Сөембикә манарасы үз астындагы кешеләр кайгысына чыдашалмый авышкан.

• Дөреслек ялгышсыз гына була, ә ялгышуда бернинди дөреслек юк.

• Ымның мәгънәсе – мең.

• Халык табагыннан ашаганнар кашык яламый.

• Һәрбер тантаналы фаҗига – мескен бәет.

Әхәт ГАФФАР

Рөстәм ЗАРИПОВ

• • •

Кемдер бүре булып яши. Кемдер
Кәҗә булып, сарык көтүендә,
Җитәкче булуын ассызыклап,
Сакалын селкетеп үтүендә...

ТОРМЫШ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ

Төшенкелек били башлый җанны,
Юк-бар шатлыкларны барламасаң...
Маңгаеңа ора кайчак тормыш,
Артка типкәннәрен аңламасаң...

БАШТА ҺӘМ АННАРЫ

Ансат кына берни килми,
Килгәнен сөзә иләк...
Оҗмахка керер өчен дә
Әвәл үләргә кирәк...

ЭШ ҺӘМ ЯЛ

"Эшләп ат үлә", дигән әйтем бар,
Эшли-эшли күпләр җөгенде...
..Берни кырмый хәлдән таеп аргач,
Туйганчы ял итү күңелле...

КЕМ ИДЕК, КЕМ БУЛДЫК...

Хайваннар исәбен алу баш санынннан,
Ә хөкүмәттәгеләрне "әгъза" санап;
Әгъзалаша партиягә кергәннәр дә,
Канәгать кыяфәтләре бер дә харап...

Язучылар берлегенә алганнан соң
Мин дә гүя маңгаемда мөһер тойдым,
Шатлыгымнан түбәтәйне күккә чөеп,
"Әгъза" булуымны танып, имза куйдым.

Фәнзаман БАТТАЛ

УФТАНМАГЫЗ!

– Үтте-китте елгыр яшьлек,
Атландырып таякка.
Шул таякта бар таяныч,
Атласам да кай якка.

– Әй ул яшьлек!.. Бер елмайсам,
Кызлар алды кочакка!
– Иллә яши белер идем,
Кайтып булса шул чакка!

– Һи-и, бу картлык... Аяк-кулда
Калмады гел җегәрлек...
Тартып карыйм уңга-сулга –
Өзеп булмый тегәрҗеп...

– Теге хаста, бу хаста
Билне бөгәләр аска.
– Яшьлек үткәч, ни хәл итмәк:
Өмет калмады башка.

... И бабайлар, уфтанмагыз,
Картлыкны тетә-тетә.
Теткән-суккәнгә карамый,
Картлык та үтеп китә!

Валентин ДРУЖИНИН

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Намус чистарак булган саен, аны кыйммәткәрәк сатып була.

Син җиде кат үлчәгәнче, башкалар кисәргә өлгерә.

Мине һәрвакыт акыллы уйлар эзәрлекли. Ләкин мин өлгеррәк...

Бездә намуслы кешеләр изгеләргә караганда сирәгрәк очрый.

Әгәр үз фикерегездә калырга телисез икән, аны эчегездә тотыгыз.

Башыңны горур тотып үрмәләү бик кыен.

Шәраб файдалы – миллионлаган ирләр берьюлы ялгыша алмый бит.

Акча килә дә китә, китә һәм китә...

(Тәҗрибә иләре мәҗлесендә язып алынды)

Сергей АНДРИАНОВ

Дамир МОРТАЗИН

Төштәге маҗаралар

Яңа елның корпоратив кичәсендә барысы да күңел ачты – генераль директордан алып иң түбән дәрәҗәдәге менеджерга хәтлесе. Эчемлекләр гөрләвектәй акты, кабымлыклар конвейердай китертелде, музыканың яңгыравына чыдамаслык түгел иде. Почмактагы өстәл артында офистагы иң чибәр Мәдинәгә шашып гашыйк булган тәэминат буенча кече специалист Ильяс газапланып утыра: ничекләр генә итеп шуны биергә чакырырга дип? Ниһаять, ул аның каршысына килеп басты. Мәдинә көлемсерәп куйды:

– Мине чакыручылар чиратка баскан, син – соңгысы...

Корпоративтан соң өйгә кайтканда, Ильяс бик нык ачынып: "Әгәр мин генеральный директор булсам, ул минем белән болай сөйләшмәс иде, – дип куйды. Шул чакта аның күңелсез уйларын итәге идәнгә хәтле җиткән тун кигән сакаллы карт бүлде. Иңнәренә капчык та аскан.

– Нәрсә, улым, кәефең юкмы әллә? – ди.

– Ә сезнең анда ни эшегез бар? – мыгырдап җавап кайтарды Ильяс.

– Минем ярдәмем тияргә мөмкин, – дип куйды карт. – Яңа елда могҗизалар килеп чыккалый, һәм хыяллар тормышка аша. Менә син нәрсә турында хыялланасың?

– Әйтик, директор булырга телим...

– Вәли Вәлиевич урынынамы?

– Әйе, – дип әйтеп куйды Ильяс.

– Шуннан тагын?

– Мәдинәгә өйләнәсем килә, – дип ычкындырды Ильяс, үзенең иң нык теләген белдереп.

– Яхшы, синеңчә булсын, – диде дә карт, капчыгын селкеп, тукталыш ягына атлады. – Өеңә кайт, йокларга ят һәм бернәрсәгә дә борчылма... – Үзе автобуска утырып әллә кая югалды.

Юрган астына кереп ятуы булды, мобильнигы шалтырап, аннан кемдер кычкырына башлады:

– Ильяс Зарипович, нишләргә? Ел ахыры, бюджет расланмаган! Иртәгә директорлар советында...

Ильяс директорлар советында нәрсә күтәсен белеп бетермәде, ниндидер хатын-кыз тавышы тәэмин итеп торучыларның төяп җибәрүне өзүләрен борчылып хәбәр итте, ә счёттан акча да алынган икән.

– Берәр карарга килегез! Сез директормы, әллә түгелме?

"Иртә белән, бөтенесе иртәгә", – диде ул йокы аралаш һәм мобильнигын сүндерде.

Икенче көнне ул үзенең эш машинасыннан чыгып, кабинетына керде. Аны анда түземсезләнеп урынбасары Борһанов көтә иде.

– Һич аңламассың, – дип башлады ул сүзен. – Барлык җаваплылар бер-берсенә салына. Бер генә эш тә эшләнми.

– Яхшы, – диде Ильяс. – Мин хәзер нәрсә булса да уйлармын...

Бернәрсә уйламыйча, төшке ашын ашады да, шофёрын чакыртып, өенә ычкынды. Ишекне халатын чак кына бөркәнеп кигән Мәдинә ачты.

– Нигә болай иртәләдең әле? – дип ризасызлык белдерде ул. – Алдан искәртеп куярга иде!

Бүлмә эчендә ниндидер ирнең гәүдәсе чалынып алды.

– Ә-ә-ә... Менә ничек икән! – дип, җан ачуы чыкканын сизми дә калды Ильяс.

– Ә син нәрсә уйладың! – дип кычкырды аңа хатыны. – Көннәр буе эштә югаласың, ә мин – яшь-яшь һәм чибәр килеш сулып ятарга тиешме?..

Ильяс, акылыннан шашкандай, шап итеп ишекне япты да урамга атылды.

"Эштә тәртип юк, өйдә хатын хыянәт итә... Ничек яшәргә? Кайда ул теге җен карт, мине мондый упкынга аткан?"

– Мин монда, җаный, монда! – дигән таныш тавыш яңгырап куйды.

– Бабакай, кирегә әйләндер әле...

– Синеңчә булсын... – диде дә карт, капчыгын селкеп, тукталышка таба атлады.

– Ниһаять, кайчан юньләп эшли башлыйбыз? Һаман хыялланасыңмы?! – дигән тавыш яңгырап алды тәэминат буенча кече специалистның колак төбендә. – Ялкауларны эштә тота алмыйм!

– Әйе, әйе, Вәли Вәлиевич! – дип куркынган тавыш белән җавап бирде Ильяс. – Бернинди хыялланулар... Мин уйга гына баттым... Тәэмин итү мәсьәләләре буенча...



Валерий ТАРАСЕНКО

Александр ШУЛЬПИНОВ

ОПЕРАТИВ ЭШ

Ульяновск өлкәсе полиция хезмәткәрләре үз эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен, акыллы комбинация үткәргәннәр. Алар Сурское авылы кешесен банк картасының урлануы турында гариза язарга күндергәннәр. Картаны урлауда гаепләнергә тиешле икенче катнашучыга биргәнәр. Ул кеше инде берничә тапкыр хөкем ителгән булган, шуңа күрә тагын бер гөнаһлы булу мөһим булмас дигәннәр, күрәсең. Ләкин нечкә исәп чынбарлыкка абынган – картада акча булмаган. Аннары полиция хезмәткәрләренең берсе, планны үтәү өчен, «урланган» карточкага 200 сум акча күчергән. Зур комбинаторларны тиз тапканнар. Шулай да бер җинаять чишелгән.

ЙОЛА МОШЕННИКЛАРЫ

Брянск шәһәренең 1 нче региональ хастаханәсенең патология бүлегенең табиблар төркеме үлгән пациентларның туганнарыннан акча җыя башлаганнар. Якыннары барысы өчен дә диярлек түләргә тиешле бәяләр исемлеге бик тәэсирле булган: җеназа залын арендалау, мәетләрне ял көннәрендә чыгару, хәтта мәет моргта яткан өчен дә. Кайвакыт бу сумма 9 мең сумга кадәр җиткән. 200 дән артык законсыз түләү очрагы исбатланган. Бүлек начальнигына – дүрт ел, төркемдәге калган хезмәттәшләренә шартлы җәза бирелгән.

ЙОМШАРТКЫЧ ШАРТ

Кемерово суды гаепләнүче өчен гадәти булмаган йомшарту хәлен тапкыр таныган. Җитди җинаятьтә гаепләнгән ирне – ул исерек килеш пистолет белән куркытып, кешегә һөҗүм иткән. Берничә тапкыр җинаять җаваплылыгына тартылуга карамастан, аңа шартлы җәза биргәннәр. Суд гаепләнүченең яшен, аның сәламәтлеген, балалары һәм йорт хайваннары булуын йомшартучы шарт дип тапканнар.

ТУЛЫ НИГЕЗДӘ

26 мең кеше яшәгән немец җәмгыятьләренең берсендә төзелеш һәм планлаштыру өчен түрә билгеләнгән. Хакимият кушуы буенча, ул өйдән эшләргә тиеш булган. Биш ел дәвамында 350 мең евролы булган, тик ул б=армакка бармак та сукмыйча, аңа хезмәт хакы даими рәвештә килеп торган. Дәүләт хезмәткәре куркыныч астында түгел – ул штат графигына һәм эш бурычларына туры китереп «эшләгән».

Сергей КОКАРЕВ

Виталий ПОДВИЦКИЙ

Фәрит ЛАТЫЙПОВ

Ә СЕЗ ЫШАНМАДЫГЫЗ!

Халык белән тулы автобус рейска чыгып китәр алдыннан бер ябык кына ир водительнең иңенә кагылды.

– Сездән сорыйсым килә, безнең автобус расписание буенча төгәл вакытта кузгаламы?

– Әйе.

– Чынлапмы?

– Ә ни өчен ул тоткарланырга тиеш? – дип гаҗәпләнде водитель.

– Көтелмәгән берәр нәрсә килеп чыкса дамы?

– Мәсәлән, нәрсә?

– Әйтик, тәгәрмәч бушаса, – дигән уйдырма белдерде ир.

– Андый очракка запастагысы бар. Китәр алдыннан шинадагы басымны да тикшердек – нормада.

– Үзегез күрдегезме?

– Юк, гараждагы дежурный.

– Шулай булгач, безнең соңга калып кузгалуыбыз бик мөмкин.

– Борчылмагыз, автобус төп-төгәл вакытта китәр, – дип, ачуланыбрак җавап кайтарды водитель.

– Тыңлагыз әле, – диде ир кеше үҗәтләнеп. – Әле генә бит шинадагы басымның төгәллеген үзегез тикшермәдегез, дидегез. Димәк, кайдан килсен сезгә автобусның соңга калмавына ышаныч.

– Тынычланыгыз, – диде водитель, моның төпченүеннән инде тәмам алҗып. – Бөтенесе тикшерелгән, каралган. Без үзебезнең эшкә бик җаваплы. Утын ташымыйбыз бит...

– Ләкин нәрсәдер килеп чыгарга да мөмкиндер, шуның аркасында автобус китә алмый кала вакытында.

– Нәрсә инде тагын? – дип тавышын күтәрде водитель.

– Мәсәлән, бензин беткән, – дигән сүз әйтеп куйды бәйләнчек ир. – Бер тапкыр без күрше белән балыкка киттек, ә ул бензин салырга онытткан. Көне буе юл кырыенда ярдәм сорап кул күтәреп тордык. Шулай да бер мәрхәмәтлесе табылды... Менә шул пүчтәк сәбәп белән без вакытында кузгала алмый калырга мөмкин!

Водитель тотлыга ук башлады.

– Бак тулы! Менә чеклары, – диде ул кәгазь кисәкләрен ирнең борын астына ук терәде һәм сәгатенә карап, йөзе үзгәреп китте. – Җен алгыры! Сезнең мәгънәсез сорауларыгыз аркасында вакытны онытып җибәргәнмен. Без бит кузгалырга тиеш!

– Менә, күрдегезме, – дип әйтеп куйды ир. – Мин бит кисәтеп тордым: нәрсә булса да килеп чыгар әле дип... Ә сез ышанмадыгыз!

Гөлчирә НӘҖМЕТДИНОВА

АКЧА МӘСЬӘЛӘСЕ

Кайтып төште өйгә ире,
Шыр исерек, сабакы.
Битендә – иннек эзләре,
Ә кулында – аракы.

Ишекне ачты хатыны:
"Кайда йөрдең, и дуңгыз!"
"Хатын, мин бит эштә булдым,
Көннәрем үтте тыгыз".

Чыгарды ире кәшилүк, –
Шыплаган акча тулы.
Алыштырып куйдылармы!
Хатынның йөзе нурлы:

"И җаныем, көн-төн эшләп,
Беткәнсең бит ватылып.
Кайларда йөрдең шулхәтле,
Сине көттем сагынып?

Әйдә, чәй эчәргә утыр,
Аннан әйбәтләп йокла.
Синең кебек уңган-булган,
Белмим, бер җирдә юк ла!"

Кәшилүк күчте хатынга,
Йокыга талды ире.
Акча хәл итте барысын,
Тынычлык кайтты кире.

Вячеслав ШИЛОВ

Александр АЛЁШИН

РЕКЛАМА

Телевизор, вертикаль пылесос, ипи пешерә торган җайланма һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Шифалы су – Ижминводы» санаториена 2 кешелек юллама!

ТАТ МЕДИА

Бүләкләрне уйнату 2024 елның 8 февралендә узачак.

ЯЗЫЛ
«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

ҖИБӘР
«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 2024 елның 22 гыйнварына кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче podpiska@tatmedia.ru

ОТ
Телевизор, вертикаль пылесос, ипи пешерә торган җайланма һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Шифалы су – Ижминводы» санаториена 2 кешелек юллама!

Өлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 2023 елның 16 ноябреннән 2024 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 22.01.2024 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемнәрдәгедән аерылырга мөмкин.

БАШ КАТЫРМЫЙЧА ГЫНА

Бер танышым, авырып киткәч, больничный алды, ә терелгәч, поликлиникага аны ябарга барды. Төрле кабинетлар буйлап чабып йөргән арада, чак кына яңа авырулар эләктермичә калды...

Бу вакыйгада авыру белән больничный арасында элемтә ап-ачык. Әмма башкача да була, кеше тап-таза, больничный кәгазе кулында – беркая да йөгерергә кирәкми. "Ничек инде алай?" – дип сорар чиратлардa иза чиккән пациент. Җавап бирәбез: хастаханәләрдә чиртсәң кан чәчрәп чыгарга торган гражданнарны эшкә ярамас чирләшкәләргә әверелдерүче конвейерлар эшләп килә.

Күптән түгел хокук сакчылары үзләренең ак халатлы ришвәтчеләр өстеннән чираттагы җиңүләре турында белдерделәр – ялган больничныйлар биргәндә Чаллы, Бөгелмә һәм Лениногорск табиблары эләккән. Чаллыдагы ашыгыч ярдәм хастаханәсенең хезмәткәрләре аеруча зур уңышларга ирешкән: температура һәм кан басымын үлчәү кебек вак-төяк белән баш катырмыйча гына, акча өчен алар бөтен теләүчеләргә диярлек больничныйлар өләшеп ятканнар. Тикшерүчеләр хәзергә 48 шундый хәлгә тап булганнар һәм 4 җинаять эше кузгатканнар. Бөгелмәдә һәм Лениногорск районында ике дистә шундый очрак булуы ачыкланган. Андагылар да шул ук гадәти тәртип буенча эш иткәннәр.

Өстә язылганнар республиканың башка төбәкләрендә барысы да ал да гөл икәнне аңлатмый, әлбәттә. Андагы "игелек кылучыларга" тикшерүчеләрнең куллары гына барып җитмәгән. Ә барып җитәчәгенә шикләнмәскә була. Ул чакта инде аларга бернәрсә дә ярдәм итмәячәк.

Ә эш вакытында ял итәргә яратучыларга бер шаян киңәш бирергә телибез: әгәр ике көн авырыйсың икән, бу турыда нәчәлнигеңә хәбәр итү дә җитә, әгәр артып китә икән – больничный алып килергә тиешсең. Ә аннан соң инде эшкә кәефең булганда гына йөри аласың!

Марсель ТАБИБОВ

Михаил ЛАРИЧЕВ

Валерий ТАРАСЕНКО

Вячеслав ШИЛОВ



Иван ХАНТЕМИРОВ, 1965 ел.

Леонид ЕЛЬКОВИЧ, 1966 ел.

УЙДА һӘМ ХЫЯЛДА

Үткәннәрне уйлап утырам... Уйланырлык та шул: бүгенгегә бәя бирү өчен бик тә гыйбрәтле гомер үткәнбез икән. Язмышыбызны үзебез көйләгән чакларыбыз да булган, көчләп ихтыярыбызга каршы хилафлык кылынган, "этлек" ясау – тыкшыну гамәлләре дә кылынган. Әлбәттә, төрле чорларда төрлечә хәлләр: махсус эшләнгәнме, ялгыш сәясәт юнәлеше корбанлык ясаганмы?.. Бу мәсьәләне илнең игътисадый хәерчелегенә бәйләргәме, әллә сәяси кытыршылыкка сылтаргамы?.. Хәер, үткәндәге вазгыятебез барыбызның да күз алдында.

Патша Россиясендәге халык тормышын безгә болай сурәтлиләр иде. Байлар бар, һәм хәерче халык. Капитализмның империячел оешуы мелитаризмга этәрелгән чагы. Инде өске катлам ил белән идарә итә алмый, ә аскы сыйныф хәерчелектә яшәргә теләми. Нәтиҗәсе – революция. Нәрсә килеп чыкканын аңлатып торасы да юк.

Хакимияттә – коммунистлар. Җир – халыкка. Сугышка – тыныслык. Колхозлашу. Халык әкренләп власть тарафыннан куелган бурычларга рухлы карашы белән кушыла. Белемсезлек бетерелә, завод-фабрикалар халыкныкы итеп игълан ителә. Илдә – гомуми күтәрелеш. Барлык омтылыш социализм төзүгә юнәлтелә. СССР куәтле илгә әверелә. Дәүләттәге милли бердәмлек илебезнең иң зур уңышы дип кабул ителә.

Мондый үсеш юлы дөньядагы бердәнбер көчле рухлы нәтиҗәгә ирештерә. 20 ел эчендә ил гигант прогресска атлый.

Ләкин дошманнар тынмый, аларны илебезнең көче куркыта, байлыгы кызыктыра, нәфесләре кайный. Бу очракта да алар нык ялгышалар.

СССРны үз өе, үз иле, үз язмышы итеп таныган, сөйгән халкы дәррәү дошманга ябырыла. Кемнәр кем булуына карамастан: завод директорымы, министрмы, эшчеме, колхозчымы, хатын-кызмы, үсмерме, газиз Ватанын сакларга китә. Әйе, аларга акча да, мал да, абруй да, югары тәхет тә кирәкми – аның аны кеше иткән, укыткан, эш биргән, дәвалаган иле бар, ул – куркыныч астында.

Мондый халыкны кем җиңә алсын! Шул хакта уйланып утырам. Хәзерге чагым минем нинди? Сез ни хәлдә, хөрмәтле Ватандашларым?

Хезмәт хакыгыз шул – минеке сыманмы? Ничек яшисез сез аңа? Балаларыгызны, оныкларыгызны укытырга акчагыз җитәме? Шулайдыр шул... Еламагыз, күз яшегезне күрсәтмәгез, барыбер алар сезнең ничек яшәгәнегезне, ничек итеп көн күргәнегезне белергә теләмиләр.

Беләм, сезнең әле һаман укыган догаларыгыз бары тик изгелеккә юнәлгән: күңелегездә әлеге дә баягы шул теләк – инде яңадан бабаларыбыз төзегән игелекле дәүләт кире кайтсын иде, дисез. Инкыйразлар, сугышлар булмасын, Ил җитәкчеләребез иманга килеп, абруйлы дәрәҗәләргә күтәрелсен, мәрхәмәтле, халкын яратучы булуга ирешсеннәр иде, дисез.

140 миллион халкыбыз шундый ният тәдер дип беләм.

Алмаз ХӘМЗИН, "Чаян".

Александр ШУЛЬПИНОВ

– Герасим, киявем белән таныш бул! Ул чит илдән – Баскервилей нәселеннән!

Александр АЛЁШИН

• • •

Иң шәп саклану – ул үзең һөҗүм итү, шуңа күрә "Аклану" язганчы, "Шикаять" язуың әйбәтрәк.

• • •

– Солы боткасыннан да туклыклырак ризык юктыр!

– Син чынлап әйтәсеңме?

– Әлбәттә! Берәү дә өстәп салуны сорамый, бер салып биргәннән соң ук туялар.

• • •

– Зәйнәп Хәйрулловна, нигә кирәге бар миңа бу алгебраның, тормышымның кайсы җирендә кулланышы чыгар аның?

– Әй Мәхмүт, 35 яшең тулгач, алтынчы класста укучы балаларың белән дәрес әзерләгәндә исеңә төшерерсең әле мине!

• • •

Бүген психологта булдым. Аңа үземнең тормышым турында сөйләдем. Елады... Көчкә туктаттым.

• • •

Бер хатын өйләнешү конторасында аңа ниндирәк ир кирәклеген аңлата:

– Ул ягымлы булырга тиеш, һәрьяклап кызыксынучан, хайваннар яратучы, төрле кызыклы хәлләр сөйли торган, дөньядагы вакыйгалар белән таныштырып торучы һәм беркайчан да мине бүлдермәүче.

– Нәрсәгә сезгә ир? Телевизор сатып алсагыз, шул җитә.

• • •

Бер картлач алтын балык тоткан, һәм ул аңа әйтә:

– Җибәр мине, синең теләсә нинди теләгеңне үтим...

– Советлар Союзы Герое буласым килә!

...һәм картлач ике граната тоткан килеш биш танк каршында калган...

• • •

Коррупциягә каршы көрәшкә бик яхшы вакытлар җитте: барысы да илдә һәм китәргә урын юк.

• • •

– Быел түрәләрнең керемнәре олигархларныкыннан артып киткән.

– Дәүләт хезмәтендә тагын нинди уңышлар бар?

Сергей КОКАРЕВ

КӨЧКӘ ИСӘН КАЛДЫК

Кадерле "Чаян"! Безнең бистәдә элеккеге "ашыгыч ярдәм" УАЗлары урынына яңа Ларгус Ладалары барлыкка килде. Бер дә борчылмыйча гына шатланасы югыйсә, әмма бистә кешеләре ни өчендер, сагынып, иске "буханка"ны сөйлиләр.

Күптән түгел миңа бу хәлнең ни өчен шулай килеп чыкканына төшенергә туры килде. "Ашыгыч" табиблары биш яшьлек кызымда сукыр эчәк үсентесенең ялкынсынуын билгеләделәр һәм Яшел Үзән хирургына барырга куштылар. Ларгуска утырганда авыруга бары тик яту өчен генә урын җайланган икән – анысы да носилкага. Баланы озата баручы якын кешесе өчен бернинди уңайлыклар булдырылмаган. Без носилканы машинадан чыгарып тормадык, шуңа мине кулларымнан тартып машинага яткырдылар да, өстемә баламны салдылар һәм нәрсәгә булса да тотынып барырга куштылар. Бистә юллары буйлап, егылып төшмәскә тырышып, баланы саклап, көчкә хастаханәгә килеп җиттек.

Шулай бара торгач, аппендициттан тыш, тагын нинди дә булса травма килеп чыкмасын дип, фельдшер баланы алдына алып утыртты. Инде башка төрле кыенлык туды – баламның башы машина түбәсенә тия булып чыкты. Табибка баскан килеш бөкрәеп барырга туры килде. Ярый әле юлда гаишниклар очрамады. Шул халәттә, ниһаять, барып җиттек.

Сүз дә юк, машина барлык реанимация чаралары белән тәэмин ителгән. Ә ул ысулларны куллану бик тә кыен икән – шулай диделәр медиклар үзләре дә.

Э. МИРОНОВА

ВАСИЛЬЕВО бистәсе
ЯШЕЛ ҮЗӘН

ГЕЛ ЯНАП ТОРГАН КУРКЫНЫЧ

Хөрмәтле редакция! Барыбызга да трамвайны алгы яктан әйләнеп, ә автобусны арттан үтәргә кирәк икәне мәгълүм. Ә менә 70 нче маршрут автобусын, гомумән, ерактан ук әйләнергә кирәк. Шунысы кызганыч, күпләр өчен бу мөмкин нәрсә түгел – менә ни өчен.

Азино-1 "Весна" торак комплексында 20 меңнән артык кеше яши, аларга бары тик 70 нче маршрутлы ике генә автобус хезмәт күрсәтә. Теоретик яктан уйлаганда, Казан үзәгенә 15 минутта барып җитәргә була. Ә чынлыкта – ай-һай... Автобуслар иске, гел ватылып тору сәбәпле, хәрәкәт интервалын чамалап булмый. Шуңа өстәп, салоннарның салкын икәнен әйтсәң, тәрәзәләренең бозга катканын өстәсәң, ямалган идәненә күзең төшсә һәм янган-көйгән истетеннәр чыгуына аптырап шаклар катарсың!.. Бу "матур" автобусларга альтернатива, әлбәттә, бар – бер якка бару өчен 500 сумлык таксилар!.. Гел аңа утырып йөреп тә булмый бит әле, кесәгә суга чөнки...

Күптән түгел генә җәмәгать транспортларына бәяләр тагын арта икән дигән сүз таралды. Шулай итмичә ярамый ди, транспорт системасына бетү куркынычы янарга мөмкин. Ә нишләп мөмкин? "Весна" торак комплексына ул инде күптән яный...

"ВЕСНА" торак комплексы халкы

КАЗАН

Язучы, журналист Дамир Гыйсметдин (Дамир Минсагыйр улы Гыйсметдинов) 1949 елның 25 гыйнварында Чуашстан Республикасының Батыр районы Татар Тимәше авылында укытучы гаиләсендә туа. 1971–1976 елларда университетның журналистика факультетында югары белем ала. Ун елдан артык (1975–1986) «Чаян» журналы редакциясендә хәбәрче, бүлек мөхәррире, бүлек мөдире булып эшли. Шул дәвердә ул үзенең сатирик каләмен чарлый, «Чаян» журналы һәм башка көндәлек матбугат битләрендә юмор-сатира жанрындагы күп кенә хикәяләрен, усал эчтәлекле фельетоннарын бастыра.

1986–1990 елларда Д. Гыйсметдин КПССның Татарстан өлкә комитетында эшли. Туксанынчы елларда халыкара «Ватан» җәмгыятенең әүвәл рәис урынбасары, аннары рәис вазыйфаларын башкара, Бөтендөнья Татар Конгрессының идарә әгъзасы була.

Дамир Гыйсметдин – юмор-сатира әсәрләре тупланган өч китап авторы («Өметсез шайтан», 1990; «Әйтсәм әйтим», 1999; «Атта да, тартәдә дә...», 2007). Ул шулай ук аерым кумәк җыентыклардагы («Таныш булыгыз, Ломжа» – «Знакомьтесь, Ломжа», 1989; «Йөртә безне язмышлар», 1992) очерк язмалары, музыкага салынган популяр җыр текстлары (унлап җыры 1999–2000 елларда чыккан «Сез яраткан җырлар» китабына кертелә) һәм төрекчәдән тәрҗемә иткән китаплар авторы буларак та укучыларга таныш.

Ул – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 2002 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде. Кызганыч, каты авырудан соң, юбилеена кадәр аз гына җитмичә, 2023 елның 5 ноябрендә вафат булды.

ТАГЫН КАЙТТЫМ

Тагын кайттым... нигә кайттым соң мин?
Кемнәр көтә монда,ниләр бар?
Яшьлек сукмакларын үлән баскан,
Дуслар киткән, көтми сөйгән яр.

Кайда соң сез, зифа ак каеннар,
Без утырткан нәни юкәләр?!
Чишмәләре кипкән тугайлардан
Сандугачлар киткән үпкәләп.

Вакыт йөге узган урамнардан,
Көмеш баскан әнкәй чәчләрен.
Авылым да карт аналар кебек
Җуйган, ахры, үзенең көчләрен.

Тагын кайттым... ничек кайтмаска соң,
Тарта тамыр, тарта туганнар...
Тау битендә яткан каберләрдән
Дәшә кебек дөнья куйганнар.

Тагын кайттым... Сагынып кайттым әле.
Йөрәкләрдә сагыш, давыл бар...
Ярый әле кайтып сыенырга өчен
Җир йөзендә туган авыл бар.

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КҮҢЕЛЕ НЕЧКӘРГӘН?

Башым салам, юкәгә сөяләм,
Моңга сусап җаннар тилмерә...
Әкрен генә «Карурман»ны сузам,
Шул җыр миңа кинәт көч бирә.

Байтак йөрдем фани дөнья буйлап,
Тоялмадым тәмен тормышның.
Сагынып кайттым изге чишмәләрне,
Салкыннарын бездәге кышның...

Бишек җыры, әнкәй моңы белән
Сеңгән җанга изге мәхәббәт.
Аның белән яшәүләре – җәннәт,
Ансыз яшәүләре – кыямәт.

Байтак йөрдем фани дөнья буйлап,
Тоялмадым тәмен тормышның.
Сагынып кайттым изге чишмәләрне,
Салкыннарын бездәге кышның...

Бар язганым ята ак кәгазьдә...
Кайсыгызның күңеле нечкәргән?
Бармы арагызда елатырлык көйче –
Кайсыгызга Ходай моң биргән?

Байтак йөрдем фани дөнья буйлап,
Тоялмадым тәмен тормышның.
Сагынып кайттым изге чишмәләрне,
Салкыннарын бездәге кышның...

КЫР ЧӘЧӘКЛӘРЕ ЮАТЫР...

Егет икәнсең – тугры бул,
Беренче мәхәббәткә.
Очма һәр көн күбәләктәй,
Чәчәктән вә чәчәккә.

Шаулый, кайный, дер селкенә –
Вулкандыр ул бу дөнья,
Дуамал чагын яратам –
Шунда матур ул дөнья.

Хыялларың күктә йөзсен,
Үзең җирдә басып тор.
Кипкән елга кебек булма –
Язгы судай ташып тор.

Шаулый, кайный, дер селкенә –
Вулкандыр ул бу дөнья,
Дуамал чагын яратам –
Шунда матур ул дөнья.

Ашыкмасаң да – ашкын син!
Ерак юлларың – такыр,
Яшәсәң яшә гөрләтеп,
Әйтерсең соңгы тапкыр.

Ашыкмый гына ашкын син,
Ерак юлларга чакыр!..
Сөюләрең шундый булсын –
Әйтерсең соңгы тапкыр!..

СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТАМ ӘНИЕМНЕ

Бәгырьләрне телеп, өметләрне өзеп,
Киттең дөньябызны ятимләп.
Өебезнең нуры, бакчабызның гөле
Бер мизгелдә сүндең, шиңдең лә.

Соңгы юлга озатам әниемне,
Кайгылардан башым әйләнде.
Ахирәтенең юлы тик берьяклы –
Кайтмас инде әни әйләнеп.

Күпме югалтулар булды бу дөньяда!
Тешне кысып, барсын кичердем,
Газиз әниемнең иртә китүләре
Сары сагыш булып киптерде.

Соңгы юлга озатам әниемне,
Кайгылардан башым әйләнде.
Ахирәтенең юлы тик берьяклы –
Кайтмас инде әни әйләнеп.

Әниләрне салкын гүргә иңдергәндә
Елый хәтта кабер ташы да.
Ак шәлләрен ябып, читекләрен киеп
Чыкмас инде әнкәй каршыма.

Соңгы юлга озатам әниемне,
Кайгылардан башым әйләнде.
Ахирәтенең юлы тик берьяклы –
Кайтмас инде әни әйләнеп.

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Хыял канатындагы бер мизгел

Һиндстан... Нинди ил икән ул? Нинди уйларга, нинди хисләргә чумасың ул сүзне ишетү белән?

Үземне хәтерләгәннән бирле мин бик гашыйкмын Һиндстан иленә. Башта ул мәхәббәт мультфильмнардан башланды. Соңыннан китаплар, һинд киносы... Хыяллана идем, киноларын карагач, мәнә мин дә һинд кызы дип. Өйдәге ситсыларны алып төренәм дә, өйдә булган бердәнбер һинд җырын тыңлап (анысы да Әлфия Авзалова башкаруында), биим.

Вакыт узган саен, ул серле илгә мәхәббәтем көчәя генә барды. Эшкә урнашу белән иң беренче соравым:

– Сездә путевкалар буламы?

– Әлбәттә, була. Санаторийга, ял йортларына.

– Юк, – мин әйтәм, – миңа анда түгел, миңа Һиндстанга барырга кирәк.

Бер еллап үтте микән, цехыбызның профсоюз җитәкчесе яныма килде дә:

– Ничек, Һиндстанга барырга һаман да телисеңме? Теләсәң, тиз генә профсоюз бүлмәсенә кер, путевка ал! – диде.

Шул әйтү җитте миңа, очтым гына. Дөрестән дә, путевка бар. Иң хыялый кеше мин булганга күрә, беренче итеп миңа әйткәннәр. Рәхмәт яугыры.

Нинди документлар кирәген, кая алып барасын өйрәттеләр. Тиз арада кирәкле язуларны җыеп, Өлкә профсоюз комитетына илтеп тә бирдем. Анда да беренче булып чыктым. Әле бер кеше дә китермәгән икән документларын. Көтәргә куштылар.

Вакыт бара, бер ай үтеп китте, икенче ай... ник чакырмыйлар икән? Барып белешергә булдым. Документларымны тапшырган бүлмәгә кердем. Андагы ханым миңа карады да:

– Сез бит әле резервта гына. Баручылар булмаса, шул вакытта сезне җибәрербез, – ди.

– Ничек резервта? Мин иң беренче булып язуларымны китердем, ә сез миңа резерв, дисез?

Уйлап-уйлап торды да бу:

– Аңлагыз, ике буш урын бар иде, тик анда үзебезнең кешеләребез бара. Менә алар бармаса...

– Бармаса да, барса да, миңа барыбер! Мин барам! – дидем дә чыгып киттем.

Өйгә кайтып җиткәнче юл буе елап кайттым.

Икенче көнне эштә бу хәлне сөйләгәч, барысының да ачулары килде.

– Башка кеше өчен кайгырмас та идек, тик менә син! Ничек инде, син бармаска тиеш? Гомерең буе хыялланган кеше! Юк, алай ярамый, обкомга хат язабыз.

Чынлап та, яздылар. Бернича көннән мине шунда чакырдылар. Ул ханым үз кешеләрен җибәрмәкче булган икән. Блат... Әмма килеп чыкмады аның бу хәйләсе. Путёвканы миңа бирделәр.

Барыр көнем килеп җитте. Дәһлигә төнлә Мәскәү аркылы очтык. Ләкин нинди йокы булсын ди? Мин бит Һиндстанга очам! Мин хыялыма ирештем! Рәхмәт яусын цехтагы дусларыма. Алар ярдәм итмәсә, хыялым чынга ашмас иде.

Дәһлигә иртәнге якта килеп төштек. Февраль ае. Салкынча һава. Бераз ял итеп алгач, шәһәр белән танышып йөри башладык. Турист булып килгәч, безгә иң матур җирләрне генә күрсәттеләр. Яхшы кунакханәләрдә яшәдек, рестораннарда ашаттылар. Башкалар аптырап карап йөрсәләр, ә мин үземне чит илгә килгән шикелле хис итмәдем. Өемдәге кебек йөрдем. Храмнары, урамнары, халык – барысы да минем өчен якын, таныш сыман.

Төрле шәһәрләрдә булырга туры килде ул вакытта. Һинд океанын да күрдем. Зур дулкыннар, кояш яктылыгындагы дулкын эчендә балыклар күренә. Нинди матурлык! Әкият. Төннәрен дә әйтеп китәсе килә. Анда кич дигән сүз юк икән. Кояш бату белән караңгылана. Ә Һинд океаны буенда һавадагы йолдызларны санап бетерерлек түгел, Ай шулхәтле зур! Аны мәңге онытмассың.

Сәяхәт вакытыбыз сизелмичә үтеп тә китте. Төш күргән сыман гына булды бу. Группадашларым сөенә-сөенә кайтырга җыена, ә мин елыйм. Кайтасым килми.

Күбесе миннән сорыйлар:

– Ничек яратасың син шул илне? Андагы шакшылык, пычрак урамнары, хәерчеләре?

Шуны әйтәсем килә: һәр кеше үзе теләгән нәрсәне күрә. Күңелең, күзең начар нәрсәне генә эзләсә, шуны гына күрәсең. Әгәр дә минем шикелле хыялый булсаң, начарлык сизелми, ахрысы.

Тискәре ягы да бар, дөрес. Ләкин менә нәрсәгә исем китте: һәр иртә хәерчеләр колонка янында юынып утыралар. Ә бездә? Чисталык, кешеләрнең фатирлары, сулары бар. Ләкин җәй көннәрендә транспортка керсәң... Яки ишегалларына... Ярый, бу турыда әйтеп тормыйм, үзегез беләсез...

Бар нәрсә дә чагыштыруда күренә шул...

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 1 (1938) гыйнвар 2024

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, РФ, РТ, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылы алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066 РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.01.2024 ел.
Тираж – 1008 Заказ С-3505
Редакциянең адресы: 420066, РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

"КАРА ... МИКӘН"

АҢ

ХӘНҖӘРНЕҢ ОЯСЫ

... БОЛЫННАРЫ

... АЛМЫЙМ" (М. НОГМАН)

... ДӘ ТУДЫМ, ... ДӘ ҮСТЕМ"

ИКЕНЧЕ НОТА

ӨСТЕНӘ БАССАҢ, МАҢГАЙГА БӘРӘ

КОМПОЗИТОР ... ЯХИН

ГОРУР ИСЕМ (ТАКТАШ)

ҖИР АСТЫНДА АЛТЫН КАЗЫК (-2)

ТӨЗЕЛЕШТӘ ДӘ, КУХНЯДА ДА

"САРЫ ... (-1)

"... КЫЗЫМ, ӘПИПӘ"

ШАГЫЙРЬ ... КАСЫЙМОВ

... БАРС

ИРКӘЛӘҮ (-1)

КӨЧЛЕ, ЧЫДАМ

71,12 см

"АГЫЙДЕЛНЕҢ ПАРОХОДЫ, БЕЗДӘН ЕРАКТА ..."

СЕБЕРДӘГЕ ЗУР ЕЛГА

Cu^{29}

САМОЛЁТ

ҖЫРЧЫ ... ИЛЬЯСОВ

ЯҢА ... БЕЛӘН!

КӨЧ- ...

"... ӘЛЕ ЯННАРЫМА"

"...ТӨЛКЕ УЙНЫЙ ТОРГАН ... БАР"

ИШАРӘ

ИРНЕҢ ТӨНГЕ ГАДӘТЕ

КӘҮСӘСЕЗ АГАЧСЫМАН ҮСЕМЛЕК

... КАБАЕВА

ЧӘЧ БУЯВЫ

"Ә АЛДЫНДА ЯРЫК ..." (ПУШКИННАН)

"БӨДРӘ ... (-1)

РЕСПУБЛИКА (АББР.)

ШАХМАТ ФИГУРАСЫ

"... БУЙЛАРЫ"

ГАЛИМ, МӘГЪРИФӘТЧЕ ... НАСЫЙРИ

АРБА ВАТЫЛСА — ...

"ХӘТЕРДӘ УЛ ... АЙЛЫ КИЧЛӘР"

ДӘҮЛӘТ ДОКУМЕНТЫ

"ДУСЛАР ... КҮҢЕЛЕМНЕ"

КУЛ- ...

"ОЛЫ ...НЫҢ ТУЗАНЫ"

... ЯГУ (НАХАК)

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

1. Нәрсә ул тормыш?

2. Икәүләп һәрвакыт җиңел булу дөресме?

3. Гаиләдә үзара гауга чыгуга бала сәбәп була аламы?

4. Базардагы каравылчы нәрсә күзли?

5. Кем ул сөяркә?

6. Допинг нәрсә ул?

7. Ир кешене кайчан "сулга" тарта?

ҖАВАПЛАР

1. Ул – бетчәләр һәм җыерчыклар чыгу мизгеле. 2. Әйе. Әгәр икенчең муенына утырмаган булса. 3. Әйе. Әгәр бала соң һәм исерек килеш кайтса. 4. Базар артын. 5. Запастагысы. 6. Сизеп тотылган чак. Сизмәгән чактагысы – витамин. 7. Хатыны һәрвакыт уңга каерса.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 12 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«БАР ГЕНӘ МИНУТКА»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Чаллыдан

Гали БАҺАВЕТДИНОВ!

КЫШКЫ ҖЕМЕЛДЕКЛӘР